ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**2017 ел 21 февраль**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 339**

2017 елгы язгы ташу чорында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы халкын һәм территориясен саклау чаралары турында

2017 елның язгы ташкын вакытында Зеленодольск муниципаль районында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм халыкны, хуҗалык һәм торак объектларны, гидротехник корылмаларны, юлларны һәм күперләрне саклау максатларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасы турында» 2003 елның 30 декабрендәге 794 номерлы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең территориаль өстәмә системасы турында» 2004 елның 10 декабрендәге 480 номерлы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елгы язгы ташу чорында Татарстан Республикасы халкын һәм территориясен саклау чаралары турында» 2017 елның 07 февралендәге 69 номерлы, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 14 июлендәге «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүнең бердәм системасы территориаль подсистемасының Зеленодольск звеносы турында»1459 номерлы карарлары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2017 елгы язгы ташу чорында Зеленодольск муниципаль районы халкын һәм территориясен саклау буенча чаралар планын ( алга таба - «План»)1 нче кушымтада каралганча расларга.
2. 2017 елның 20 мартыннан 1 маена кадәр язгы ташу чорында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе әгъзаларының кизү тору графигын 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. 2017 елгы язгы ташуга каршы чараларны гамәлгә ашыру буенча Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча эш төркеме составын 3 нче кушымтада каралганча расларга.

4. Зеленодольск муниципаль районы халкын һәм территориясен язгы ташуга әзерлек һәм аны узу чорында чаралар комплексын тәэмин итү буенча чараларның үтәлешен тикшерү өчен 4, 5, 6, 7 нче кушымталарда каралганча дүрт оператив төркем расларга.

5. Зеленодольск муниципаль районы предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләренә, Зеленодольск муниципаль районы авыл (шәһәр) җирлекләре Башлыклары һәм Башкарма комитетлары җитәкчеләренә (кагыла торган өлештә)түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән язгы ташу чорында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы халкын һәм территориясен саклау буенча чаралар планын үтәү өчен кабул итәргә;

2017 елның 1 мартына кадәр язгы ташуга каршы тору комиссияләре һәм язгы ташу суларын кабул итү һәм үткәрү буенча махсус бригадалар төзергә;

2017 елның 1 мартына кадәр язгы ташу чорында персоналны, халыкны һәм аларга буйсынган территорияләрне саклау чаралары планын эшләргә;

2017 елның 1 мартына кадәр 2017 елның язгы чорында җирлек территориясендә су басу күренешләренә бәйле гадәттән тыш хәлләрне булдырмау һәм алардан килгән зыяннарны бетерү буенча оператив планны (алга таба текст буенча - «Язгы ташу» оператив планын) төзәтергә; аны үтәү өчен җәлеп ителә торган көчләрнең һәм чараларның үзара хезмәттәшлеген оештырырга;

халыкка хәбәр итүнең мөмкин булган барлык ысулларын исәпкә алып, тиз арада хәбәр итү тәртибен һәм схемасын эшләргә;

су арту дәрәҗәсе югары булган, су басу һәм ташу күздә тотылган биналар, инженерлык корылмалары, коммуникацияләр, автомобиль юллары өчен даими контроль урнаштырырга;

су басу зонасына эләккән эвакуацияләнгән халыкның вакытлыча урнашу урыннарын (вакытлыча урнаштыру пунктларын) аларның беренче чираттагы тормыш кирәк- яракларын исәпкә алып әзерләүне һәм тикшерүне оештырырга;

язгы ташу вакытында кичектергесез эшләр башкару өчен матди ресурсларның кирәкле запасларын әзерләргә;

Зеленодольск муниципаль районының Идел елгасы, Зөя елгасы, кече елгалары һәм сулыклары өчен җаваплы затларны билгеләргә;

язгы ташу чорына мөмкин булган су басу зоналарында урнашкан торак пунктлар кибетләрен сәнәгать товарлары һәм беренче кирәк-ярак продуктлары белән тәэмин итү эшен оештырырга;

җирлек территориясендә булган гидротехник корылмаларның һәм су үткәрү системаларының инженерлык системаларының торышын һәм эшкә яраклылыгын тикшерүне оештырырга.

6. «Зеленодольск муниципаль районының Торак-коммуналь хуҗалыгы департаменты» МБУ җитәкчесе О.В. Анисимовка, «Коммуналь хуҗалык» МУП директоры А.И. Нигъмәтуллинга, «Волгадорстрой» ҖЧҖ генераль директоры А.А.Миңнуллинга, «Восток» ЦТО ҖЧҖ директоры М.Г. Оюшинга, «Нурлат юллары» ҖЧҖ генераль директоры И.И.Яруллинга , ТКХ МПП җитәкчеләренә, Зеленодольск муниципаль районы җирлекләре Башлыклары һәм Башкарма

комитетлары җитәкчеләренә кюветларны, су агызу торбаларын һәм канауларны, яңгыр канализациясен чистарту эшен оештыруны, юлларның, юл үткәргечләрнең, күперләрнең, тротуарларның һәм башка инженерлык корылмаларының торышын күзәтүне, автомобиль юлларының юылуына юл куймаска тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның 6 пунктында күрсәтелгән чараларны үтәү өчен җаваплы итеп «Зеленодольск муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалык департаменты» МБУ җитәкчесе О.В. Анисимовны (шәһәр буенча), Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.О. Котельниковны (район буенча) билгеләргә.

8. Россия Эчке эшләр министрлыгының Зеленодольск районы буенча бүлеге начальнигына полиция полковнигы А.Р.Ханбиковка түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

халыкны үз участокларында су агызу канауларын чистартуга җәлеп итү максатыннан, шәхси секторлар ишегалдында йөреп чыгу өчен полиция хезмәткәрләрен (участок вәкаләтлеләрен) җибәрүдә «Зеленодольск муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалык департаменты» МБУга ярдәм күрсәтергә;

язгы ташу чорында шәхси составның югары әзерлеген тәэмин итәргә.

9. Зеленодольск муниципаль районында язгы ташуга бәйле гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү чараларын уздыру чорында тотрыклы, өзлексез элемтәне тәэмин итү чараларын күрүне «Таттелеком» ААҖ филиалы Казан ЗУЭСының Зеленодольск район электр элемтәсе узелы начальнигына Е. А. Носковка тәкъдим итәргә.

10. район халкын су белән тәэмин итү системаларында суның сыйфатына лаборатор контрольне көчәйтергә Зеленодольск, Югары Ослан, Кама Тамагы районнарында «Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең РТ (Татарстан) территориаль бүлеге» начальнигы Е.К. Агеевага Зеленодольск, Югары Ослан, Кама Тамагы районнарында «Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге»ФБССУ филиалының баш табибы В.В. Гасилинга тәкъдим итәргә.

11. Зеленодольск муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Т.Г. Җиһаншинга, Зеленодольск район дәүләт ветеринария берләшмәсенең баш табибы Ф.И. Фәхретдиновка авыл хуҗалыгы объектларын, үләт базларын (биотермик чокырларны), шул исәптән су басу ихтималы булган зонага эләккән себер түләмәсе үләт базларын тикшерүне оештырырга тәкъдим итәргә.

12. «Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы И.Р. Хидиятовга түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

язгы ташу чорында халыкка үз вакытында медицина ярдәме күрсәтү өчен ашыгыч медицина ярдәме бригадаларының һәм шәһәр һәм район медицина учреждениеләренең әзерлеген тәэмин итәргә;

фельдшер-акушерлык пунктларының дарулар һәм дару препаратлары, шул исәптән шикәр диабеты белән авыручыларның тормышларын тәэмин итү өчен кирәкле дарулар белән тәэмин ителешен шәхси контрольгә алырга.

13. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының кулланучылар базары бүлеге башлыгы Д.Г. Низамовка язгы ташу чорында су басу мөмкин булган зоналарда урнашкан торак пунктлар кибетләрен сәнәгать товарлары һәм беренче кирәк-ярак продуктлары белән тәэмин итүне контрольдә тотуны оештырырга.

14. «Татарстан Республикасы буенча ФПС 8 нче отряды» ФДУП башлыгы З.М. Хәлиуллинга түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Зеленодольск муниципаль районының язгы ташу чорында янгын сүндерү техникасын үтү мөмкинлеге булмаган торак пунктларында янгын сүндерүне оештыру тәртибен билгеләргә. Әлеге торак пунктларны янгын сүндерү техникасы белән тәэмин итәргә һәм анда тәүлек буе кизү торуны оештырырга;

предприятиеләрнең, оешмаларның янгын сүндерү өчен җайлаштырылган автотехникасы исемлеген төгәлләштерергә, су басу белән киселгән торак пунктларда һәм объектларда янгыннарны сүндерү өчен аларны җәлеп итү тәртибен билгеләргә;

күчмә, прицеплы мотопомпаларны, йөзү чараларын исәпкә алырга һәм хәрби исәпләүгә кертергә, вертолет мәйданчыкларын ашыгыч рәвештә җәелдерү өчен кирәкле җиһазлар әзерләргә һәм аларның су басу чорына төшү мөмкин булган урыннарын билгеләргә;

«Татарстан Республикасы буенча ФПС 8 нчеотряды» федераль дәүләт казна учреждениесеннән су басу характерындагы һәлакәтләргә җавап бирүгә оператив төркемнәр оештырырга һәм аларның әзерлеген тәэмин итәргә;

Су басу чорында гадәттән тыш хәлләргә һәм һәлакәтләргә җавап бирергә әзер булырга, шулай ук су басу зонасында калган кешеләрне эвакуацияләүне һәм коткаруны оештырырга.

15. Россия Федерациясе Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча ГХМ ГИМС Үзәгенең Зеленодольск инспектор бүлекчәсе башлыгы С.Ю. Евсеевка җирлекләрнең Башкарма комитетлары җитәкчеләре, Зеленодольск муниципаль районы предприятиеләре, оешмалары җитәкчеләре белән берлектә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

су объектларында кешеләр үлемен кисәтү һәм киметү буенча халык арасында аңлату эшләре уздыруны оештырырга;

җиһазландырылмаган урыннарда, шулай ук язгы ташу чорында елга бозларына һәм сулыкларга автотранспорт һәм җәяүлеләр чыгуын булдырмау эшен оештырырга.

16. ТР буенча РФ ГТХМның УНД һәм ПР ГУ Зеленодольск муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш бүлеге начальнигы эчке хезмәт полковнигы Р.Р. Ардыхановка тәкъдим итәргә:

янгын куркынычсызлыгы мәсьәләләре буенча, шул исәптән электр җылыту, җылыту, газ һәм башка янгын куркынычсызлыгы приборларын куллану кагыйдәләре буенча, мөмкин булган су басу(су ташу) зонасына эләгүче халык (предприятие һәм оешма хезмәткәрләре) арасында аңлату һәм профилактика эшен үткәрергә.

17. Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм милләтара мөнәсәбәтләр бүлеге башлыгы А.Н. Коршуновка түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

язгы ташу чорында Зеленодольск муниципаль районы халкының иминлеген тәэмин итү өлкәсендә массакүләм мәгълүмат чаралары аша мәгълүмат-пропаганда эше оештырырга;

Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының (http:zelenodolsk.tatarstan.ru)рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә .

18. «2016 елгы язгы ташу чорында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы халкын һәм территорияләрен саклау чаралары турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 26 февралендәге 417 номерлы карарын үз көчен югалткан дип санарга.

19. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Зеленодольск муниципаль районының ГО һәм ГТХ эшләре идарәсе» МБУ өстенә йөкләргә.

Җитәкче
А.Х.Сәхибуллин

ЗМР Башкарма комитетының
2017 елның 21 февралендәге
339 номерлы карарына
1 нче кушымта

**2017 елгы язгы ташу чорында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы халкын һәм территориясен саклау чаралары планы**

| № т/б | Чаралар исеме | Башкаручылар | Башкару срогы |
|---|---|---|---|
| | **Оештыру чаралары** | | |
| 1. | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «УГМС» ФДБУ тарафыннан алына торган авыл җирлекләре башлыкларына, оешмалар , предприятиеләр һәм учреждениеләр җитәкчеләренә көтелгән язгы ташу характеристикаларын, елгалардагы суның максималь дәрәҗәләре фаразларын, Идел-Кама каскады сусаклагычына су агызу фаразларын вакытында илтеп җиткерү | ЗМР Бердәм дежур диспетчерлык хезмәте (ЕДДС) | ташу башланганчы һәм чорында |
| 2. | Язгы ташу чорында персоналны, халыкны һәм аларга буйсынган территорияне саклау чаралары планын эшләү | Җирлекләренең Башкарма комитетлары Башлыклары һәм җитәкчеләре, ЗМР предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре | 01.03.2017 кадәр |
| 3 | Су басуга каршы чараларны гамәлгә ашыру буенча КЧС һәм ПБ объектларының эш төркемнәре составын билгеләү, 2017 елның язгы ташкынына предприятиеләргә әзерлек буенча чараларның үтәлешен тикшерү графигын төзү | Җирлек Башлыклары һәм Башкарма комитет җитәкчеләре, ЗМР предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре | 01.03.2017 кадәр |
| 4 | Язгы ташу нәтиҗәләрен киметү һәм бетерү өчен ашыгыч чаралар күрүне таләп итә торган мәсьәләләрне даими карау | Җирлек Башлыклары һәм Башкарма комитет җитәкчеләре, ЗМР предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре | язгы ташу чорында |
| 5 | Авыл (шәһәр) җирлекләре башлыкларына һәм башкарма комитетлары җитәкчеләренә, Зеленодольск муниципаль районы предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләренә кисәтү һәм су басуга каршы чаралар әзерләүдә һәм уздыруда оештыру-методик ярдәм күрсәтү | ЗМР КЧС һәм ПБ эш төркеме, ГО һәм ГТХ эшләре идарәсе | ташу башланганчы һәм чорында |
| 6 | ЗМР ГО һәм гадәттән тыш хәлләр эшләре идарәсенә контакт телефоннары, күрсәтмәләр, су басуга каршы чараларны планлаштыру турында | Җирлек Башлыклары һәм Башкарма комитет җитәкчеләре, ЗМР предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре | 01.03.2017 кадәр |

| № т/б | Чаралар исеме | Башкаручылар | Башкару срогы |
|---|---|---|---|
| | боерыкларны күрсәтеп, су басуга каршы комиссияләр составы, су басуга каршы чорга әзерлек барышы турында мәгълүмат бирү | җитәкчеләре | |
| 7 | Объект дәрәҗәсендәге КЧС һәм ПБ утырышларын язгы ташуга әзерлек мәсьәләсе буенча киңәшмәләр үткәрү | су басу мөмкин булган зонага эләгүче җирлекләр Башлыклары һәм Башкарма комитетлары җитәкчеләре, ЗМР предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре. | 20.03.2017 кадәр |
| 8 | Районның су объектларында су дәрәҗәсен, потенциаль куркыныч һәм авария хәлендәге гидротехник корылмаларның торышын тикшереп тору өчен вакытлы күзәтүчелтәре эшләвен оештыру | ЗМР КЧС һәм ПБ , ЗМР җирлекләренең Башкарма комитетлары Башлыклары һәм җитәкчеләре, предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре | язгы ташу чорында |
| 9 | Халыкны, авыл хуҗалыгы хайваннарын һәм матди кыйммәтләрне язгы ташу яки су басу дулкыны булган су басу зоналарыннан өлешчә эвакуацияләү планнарын төзәтү, эвакуацияләнгән халыкны вакытлыча урнаштыру пунктларын билгеләргә | ЗМР КЧС һәм ПБ , ЗМР җирлекләренең Башкарма комитетлары Башлыклары һәм җитәкчеләре, предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре | 20.03.2017 кадәр |
| 10 | Халыкка хәбәр итү системасының эшкә яраклыгын , Зеленодольск муниципаль районының ПБ КЧС оператив җыемын тикшерергә | ЗРУЭС, җирлек Башлыклары һәм Башкарма комитет җитәкчеләре, ЗМР предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре | 15.03.2017 кадәр |
| 11 | Су басу зонасына эләгә торган торак пунктлар белән элемтә оештыру, көчләр һәм элемтә чаралары исәбен алып бару | ЗРУЭС, җирлек Башлыклары һәм Башкарма комитет җитәкчеләре, ЗМР предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре | 15.03.2017 кадәр |
| 12 | Зеленодольск муниципаль районы территориясендә язгы ташу чорында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өлкәсендә мәгълүмат җыюны һәм эшкәртүне, шулай ук әлеге мәгълүматны кызыксынган предприятиеләр һәм оешмалар белән алмашуны гамәлгә ашыру | ЗМР Бердәм дежур диспетчерлык хезмәте(ЕДДС) | ташу башланганчы һәм чорында |
| 13 | Язгы ташу белән бәйле гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен халыкка җиткерү | Җирлек Башлыклары һәм Башкарма комитет җитәкчеләре | ташу башланганчы һәм чорында |
| | **Практик чаралар** | | |
| 1. | Гидротехник корылмаларны (инженерлык саклау объектлары, буалар, плотиналар, дамбалар һ. б.) эрегән суның максималь күләмнәрен үткәрүгә әзерләү буенча эшләрне оештыру | Җирлек Башлыклары һәм Башкарма комитет җитәкчеләре, ЗМР предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре | 10.03.2017 кадәр |
| 2 | Ремонт процессында булган җитешсезлекләрне һәм кышкы чорның | Гидротехник корылмалар милекчеләре, эксплуатацияләүче | ташу башланганчы |

| № т/б | Чаралар исеме | Башкаручылар | Башкару срогы |
|---|---|---|---|
| | тискәре нәтиҗәләрен вакытында ачыклау һәм бетерү максатыннан гидротехник корылмаларны (плотиналар, дамбалар, насос станцияләре һ. б.) һәм мелиоратив системаларны кабат тикшерүне оештыру | оешмалар, җирлек Башлыклары һәм Башкарма комитет җитәкчеләре | һәм чорында |
| 3 | Барлык гидротехник корылмалар фронты буенча су сиптерү тишекләре аша бозның ваклануын оештыру буенча оператив чаралар күрү | Гидротехник корылмалар милекчеләре, эксплуатацияләүче оешмалар, җирлек Башлыклары һәм Башкарма комитет җитәкчеләре | язгы ташу чорында |
| 4 | Аеруча куркыныч урыннарда көчле су басулар фаразланган очракта инженерлык саклау корылмаларын күзәтү көчәя, хәтта тәүлек әйләнәсе дежурлык һәм ышанычлы хәбәр итү һәм элемтә системасы оештырыла | Гидротехник корылмалар милекчеләре, эксплуатацияләүче оешмалар, җирлек Башлыклары һәм Башкарма комитет җитәкчеләре | ташу башланганчы һәм чорында |
| 5 | Су басуны булдырмау буенча контрольне гамәлгә ашыру:<br>- сыек калдыклар тупланган районнарда, чистарту корылмаларында һәм агулы химикатлар саклана торган урыннарда;<br>- биотермик чокырлар һәм себер түләмәсе үләт базларында | «Зеленодольск - Водоканал» предприятиесе - «Водоканалсервис» ААҖ филиалы, АҖ башлыклары, «Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор территориаль идарәсенең территориаль бүлеге» бүлеге) Зеленодольск, Югары Ослан, Кама Тамагы районнарында, «Татарстан Республикасында гигиена һәм эпидемиология үзәге» ФБССУ филиалы, Зеленодольск, Югары Ослан, Кама Тамагы районнарында, Зеленодольскрайоны дәүләт ветеринария берләшмәсе, Җирлек Башлыклары һәм Башкарма комитет җитәкчеләре, ЗМР предприятие, оешмалар һәм учреждениеләре җитәкчеләре | 20.03.2017 кадәр оештыру чаралары; практик чаралар - ташу чорында |
| 6 | Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск муниципаль районы юлларында эрегән суларның максималь күләмнәрен үткәрү өчен су үткәрү торбаларын, яңгыр агымын, каналларны, яңгыр канализациясе корылмаларын чистарту буенча чаралар үткәрүне оештыру | «Торак комплексы» ИК» ҖЧҖ, «ЗВКС» АҖ, «Волгадорстрой» ҖЧҖ, «Восток» ЦТО ҖЧҖ, «Норлат юллары» ҖЧҖ, ТКХ МПП җитәкчеләре, Җирлек башлыклары һәм Башкарма комитет җитәкчеләре, ЗМР предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре | ташу башланганчы һәм чорында |
| 7 | Ташлама узу мониторингын гамәлгә ашыру; торак биналарны һәм инфраструктура объектларын су басу куркынычы ачыкланган очракта кичекмәстән һәлакәт-коткару эшләрен оештыру һәм уздыру буенча чаралар күрү | Җирлек Башлыклары һәм Башкарма комитет җитәкчеләре, ЗМР предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре | язгы ташу чорында |
| 8 | Су басу мөмкинлеге булган зонага эләгә торган трансформатор | Зеленодольск районы электр челтәрләре , Свияжск | 20.03.2017 елга |

| №<br>т/б | Чаралар исеме | Башкаручылар | Башкару срогы |
|---|---|---|---|
| | подстанцияләре коммуникацияләрен, электр белән тәэмин итү һәм элемтә кабель линияләрен тикшерү. Аларны имин эксплуатацияләү чараларын күрергә | районы электр челтәрләре, «Зеленодольскгаз»ЭПУ, ЗРУЭС, җирлек Башлыклары һәм Башкарма комитет җитәкчеләре һәм башка предприятие , электр белән тәэмин итү һәм элемтә линияләренә хезмәт күрсәтүче коммуникацияләр һәм элемтә оешмалары җитәкчеләре | кадәр һәм язгы ташу чорында |
| 9 | Күперләрне тикшерү һәм ныгыту, түбән булган күперләрне саклауны оештыру, материаллар һәм аларны торгызу өчен чаралар әзерләү. Вакытлы кичү урыннарын билгеләү | Җирле Башлыклары һәм Башкарма комитет җитәкчеләре, «Волгадорстрой» ҖЧҖ, «Восток» ЦТО ҖЧҖ, «Норлат юллары» ҖЧҖ | ташу башланганчы һәм чорында |
| 10 | Язгы ташкын вакытында автомобиль юлларының һәм ясалма корылмаларның әзерлеген һәм аларны карап тоту дәрәҗәсен тикшерүне оештыру | «ЗМР ТКХ департаменты» МБУ, «Волгадорстрой» ҖЧҖ, «Восток» ЦТО ҖЧҖ, «Норлат юллары» ҖЧҖ, җирлек Башлыклары һәм Башкарма комитет җитәкчеләре | ташу башланганчы һәм чорында |
| 11 | Су басу ихтималы булган зоналарга эләгүче торак биналардан һәм халыкның тормыш тәэмин итү системалары объектларыннан эрегән суларны читкә җибәрү буенча эшләрне оештыру. | «Торак комплексы» ИК» ҖЧҖ, җирлек Башлыклары һәм Башкарма комитет җитәкчеләре, ЗМР предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре | язгы ташу чорында |
| 12 | Ашыгыч авария-торгызу эшләре башкарылган очракта йөзү чараларын, инженерлык, юл-төзелеш һәм башка кирәкле техниканы әзерләү, аны тиешле күләмдә ягулык һәм майлау материаллары белән тәэмин итү | Җирлек Башлыклары һәм Башкарма комитет җитәкчеләре, ЗМР предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре | 20.03.2017 кадәр |
| 13 | Гадәттән тыш хәлләрне һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү өчен запаслар булдыру:<br>- финанс, матди-техник чаралар буенча;<br>- гадәттән тыш хәлләрне һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү өчен инертлы һәм сайлау материалларын;<br>- су әзерләү предприятиеләрендә зарарсызландыру чаралары | Җирлек Башлыклары һәм Башкарма комитет җитәкчеләре, ЗМР предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре | 20.03.2017 кадәр |
| 14. | Язгы ташуда һәм су басуда зыян күргән кешеләргә медицина ярдәме күрсәтүне оештыру буенча әзерлек эшләре алып барырга. Медикаментларның кирәкле резервын тәэмин итәргә | «ЗЦРБ» ДАССУ баш табибы, шәһәр (шәһәр) җирлекләре Башлыклары һәм Башкарма комитет җитәкчеләре, | 20.03.2017 кадәр |
| 15 | Язгы ташу чорында зыян күргән халыкны беренче вакытта тормыш өчен кирәк-ярак белән тәэмин итү өчен әзерлек эшләре башкару | ЗМР ,КЧС һәм ПБ, җирлекләренең Башлыклары һәм Башкарма комитетлары җитәкчеләре. | ташу башланганчы һәм чорында |
| 16 | Боз катламының торышын һәм район елгаларындагы суларның дәрәҗәсен күзәтүне оештыру. | Җирлек Башлыклары һәм Башкарма комитет җитәкчеләре, ЗМР предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре | язгы ташу башланганчы һәм узганчы. |
| 17 | Халыкны үзәкләштерелмәгән су белән тәэмин итү чыганакларын су | Авыл җирлекләре Башлыклары һәм Башкарма комитетлары | ташу башланганчы |

| № т/б | Чаралар исеме | Башкаручылар | Башкару срогы |
| --- | --- | --- | --- |
| | басуны, ташуны булдырмауга юнәлдерелгән профилактик чаралар үткәрү | җитәкчеләре. | һәм чорында |
| 18 | Торак пунктларның эчәр торган су белән тәэмин итү чыганакларын су басу, ташу очрагына эчәр су китерүчеен шартлар тудыру | Авыл җирлекләре Башлыклары һәм Башкарма комитетлары җитәкчеләре. | язгы ташу башланганчы һәм узганчы. |
| | **Контроль чаралар** | | |
| 1. | Җирлекләр Башлыкларын, торак-коммуналь, юл, энергетика, медицина предприятиеләре һәм оешмалары җитәкчеләренең язгы ташуга әзерлекләре турында тыңлау. | ЗМР КЧС һәм ПБ | 20.03.2017 кадәр |
| 2. | Эчәр торган суның сыйфатын, ачык су чыганакларының халыкны эчәргә яраклы су белән тәэмин итү өчен кулланыла торган су җыю җайланмаларының су басу урыннарының торышын санитар-эпидемиологик тикшереп торуны оештыру | Зеленодольск, Югары Ослан, Кама Тамагы районнарында Татарстан Республикасы буенча Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт идарәсенең (Татарстан) территориаль бүлеге, Зеленодольск, Югары Ослан, Кама Тамагы районнарында «Татарстан Республикасында гигиена һәм эпидемиология үзәге» ФБУЗ , «ЗВКС» АҖ, Җирлек башлыклары | язгы ташу чорында |
| 3. | Су басу чоры чараларын әзерләүне һәм уздыруның сыйфатын тикшереп торуны оештыру | ЗМР КЧС һәм ПБ, ГО һәм ГТХ эшләре идарәсе | ташу ахырына кадәр |
| 4. | Зеленодольск муниципаль районы территориясендә язгы ташу узу турында халыкка вакытында хәбәр итү | ЗМР ГО һәм ГТХ эшләре идарәсе, "ТР буенча 8 нче ФПС отряды" ФГКУ Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ТР буенча идарәсенең ЗМР буенча идарәсе,Зеленодольск шәһәре УМЦ һәм ЧС, ЮХИДИнең Зеленодольс бүлекчәсе, "Зелёный Дол", "Зеленодольская правда", "Яшел Үзән" газеталары редакцияләре, "Яшел Үзән" мәгълүмат үзәге, "Яшел Үзән" ААҖ филиалы, «Зелёный Дол», мәгълүмат үзәге, җирлекләренең башлыклары һәм Башкарма комитетлары җитәкчеләре, предприятие, оешма һәм учреждение җитәкчеләре | ташу башланганчы һәм чорында |